**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2019 елның «18» апреленнән № 105

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан муниципаль район составына керүче авыл җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен раслау турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен раслау турында» 2019 ел, 28 март, 233 нче карары нигезендә, һөнәри табышка салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан муниципаль район составына керүче авыл җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**

Яңа Чишмә
муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
Карары белән расланган 105
«18» нче апрель 2019 ел

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан муниципаль район составына керүче авыл җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан муниципаль район составына керүче авыл җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, җирлекләр).

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында, муниципаль район составына керүче авыл җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итү өчен бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар җирлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан тиешле финанс елына һәм план чорына әлеге максатларга кирә торган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә узган кварталдан соң килүче айның 30 числосына кадәр бирелә.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын төп бүлүче булып Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (алга таба – финанс-бюджет Палатасы) тора.

5. Башка бюджетара трансфертларны бүлү Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннанраслана.

6. Тиешле квартал өчен I-нче җирлеккә башка бюджетара трансфертлар күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән исәплү методикасы нигезендә билгеләнә..

7. Авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шарты булып муниципаль район составына керүче җирлекнең башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның юнәлешен билгели торган норматив хокукый акты булу тора.

8. Башка бюджетара трансфертлар Финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирлекләр бюджетларына җирле бюджетларның үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетына күчерелә.

9. Җирлекләрнең башкарма комитетлары (алга таба – башкарма комитетлар) Финанс-бюджет палатасына башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә отчет тапшыралар.

10. Әлеге Тәртип нигезендә алынган һәм агымдагы финанс елның 1 гыйнварына тотылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Финанс-бюджет палатасы тарафыннан узган финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турында карар нигезендә, әлеге башка бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар агымдагы финанс елында моңа кадәр бирелгән җирлек бюджеты кеременә әлеге башка бюджетара трансфертлар бирүнең тиешле максатларына туры килә торган бюджет чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен кире кайтарылырга мөмкин..

Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыклары Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты кеременә кайтарылмаган очракта, әлеге акчалар Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәү максатында, Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

11. Башкарма комитетлар һәм вазыйфаи затлар тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү өчен законнар нигезендә җаваплы.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты кеременә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

13. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны Финанс-бюджет палатасы гамәлгә ашыра.